КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 февраль г.Казань № 115

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 802 нче карары белән расланган «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 802 нче карары белән расланган «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашырганда үзара ярдәм итешү турында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән килешү төзегән катнашучы предприятиеләр – оешмалар.»;

10 пунктның беренче абзацында «2019 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин